**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**
**өченче чакырылыш утызенче утырыш**

**25.10.2019 ел** **№ 126** **Олы Нырсы авылы**

**Татарстан Республикасы**
**Теләче муниципаль районы**
**«Олы Нырсы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына**
**үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 80-82 статьялары нигезендә, Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлеге Советы **карар итте:**

**1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«5 статья. Авыл җирлегенең җирлек әһәмиятендәге сораулары.**

1. Авыл җирлегененең җирлек әһәмиятендәге сорауларына түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм кире кагу;

3) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) ял вакытын оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) җирлекнең архив фондларын булдыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

10) адрес объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адресы реестрында урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

16) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек биләмәсендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкына массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректе үтүен тәэмин итү.».

**2. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муницииаль берәмлеге Уставының 6 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«6 статья. Җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә Җирлекнең җирле үзидарә органнары хокуклары.**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирлекнең музейларын булдыру;

2) җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне кылу;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

4) җирлек биләмәсендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә ярдәм күрсәтү һәм җирлек биләмәсендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

6) җирлек биләмәсендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

7) муниципаль янгын сагын булдыру;

8) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

9) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

10) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмалары тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

11) үз көчен югалту.

12) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан гражданнарга торак урыннары бирү;

13) җирлек территориясендә яшәүче хуҗсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

15) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итү.

16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге N 2300-1 Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.

2. Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга («Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаган) хокуклы, әгәр дә бу катнашу федераль законнарда каралган булса, шулай ук башка муниципаль

берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән үз компетенцияләреннән төшереп калдырмаган башка мәсьәләләрне, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм өстәмә түләүләр нормативлары буенча салым керемнәре буенча сорауларны хәл итәргә хокуклы.».

**3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 9 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**« 9 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу.**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне дә кертеп, җирлектә муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәткәрнең статусын билгеләү, муниципаль хезмәтне үтү шартлары һәм тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге№ 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

**4. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«22 статья. Гражданнар җыены.**

1. Гражданнарның җыены халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы рәвеше булып тора.

2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә нисбәтле үткәрелә.

3. Гражданнар җыены муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан йә сайлау хокукына ия, торак пунктта яшәүче, кимендә 10 кешедән торган, төркем инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

4. Җыенны уздыру инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия гражданнарның, даими яисә өстенлекле рәвештә яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән санының 5 процентын тәшкил итәргә тиеш, әмма 25 имзадан да ким була алмый.

5. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы карары, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.

6. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында, нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә, муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан ук билгеләнә. »

7. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге статья белән карала торган гражданнар җыены хокукка ия дип санала, әгәр дә җыенда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яисә Җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыграгы катнашса. Әлеге гражданнар җыенының карары кабул ителгән дип санала, әгәрдә аңа гражданнар җыенында катнашучыларны да яртысыннан күбрәге тавыш бирсә.

9. Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены әлеге торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләренең яртысыннан артыграгы катнашса хокукка ия дип санала. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан артмаган вакытта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар.».

**5. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

5.1. 1.11 пунктчасының 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.11) төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнаша;

-Җирлек территориясен төзекләндерә (урамнарны яктыртуны да кертеп, территорияне яшелләндерүне, урамнар һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп;

- җирлек территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп тора;

- адрес объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртә, гамәлдән чыгара ала, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирә, мондый исемнәрне үзгәртә, гамәлдән чыгараала, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыра.»

5.2. 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлекнең башкарма комитеты җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- җирлек музейларын төзи;
- җирлектә нотариус булмаган очракта, кануннарда каралган нотариаль гамәлләрне кыла;
- опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша;
- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;
- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм итә;
- җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;
- муниципаль янгын сагын төзи;
-«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;
- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;
- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән оешмаларга, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтә;
- гражданнарга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын, наем шартнамәләре буенча, торак законнары нигезендә бирә;
- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;
- инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итә;
- «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.

**6. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 49 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«49 статья. Муниципаль контроль.**

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контроль оештыралар һәм гамәлгә ашыралар, ә федераль законнарда тиешле контроль төрләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән очракларда, шулай ук федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контроль үткәрләр.

2. Авыл җирлегенең муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы - җирлекнең Башкарма комитеты. Авыл җирлегендә муниципаль контроль вазыйфаи зат йә җирлек Башкарма комитетының структур бүлекчәсе, авыл җирлеге Башлыгы вәкаләт биргән вәкаләтле вәкил тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контроль өлкәсендә Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә алып барыла;

1.1) җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан раслана торган типлы административ регламентлар нигезендә җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

3) федераль законнарда, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләрен җирлекнең башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә йөкләргә мөмкин.

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

**7.«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын VIII бүлек белән тулыландырырга. Муниципаль хезмәтне узу һәм муниципаль вазыйфаларны биләү, түбәндәге эчтәлекле:**

## « VIII бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮ.

### 54 статья. Гомуми нигезләмәләр.

1. Муниципаль хезмәт- гражданнарның, хезмәт шартнамәсен (контрактын) төзү юлы белән билгеләнә торган, муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган һөнәри эшчәнлек.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән раслана торган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәтне финанслау Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнар муниципаль хезмәттән тигез файдалана алалар һәм аны җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга нисбәтсез рәвештә тигез хокуклы булалар.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы законы белән муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә билгеләнә торган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

### 55 статья. Муниципаль хезмәт вазыйфасы.

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - Сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләренең үтәлешен тәэмин итү буенча билгеләнгән йөкләмәләр даирәсе белән куелган, әлеге Устав нигезендә барлыкка килә торган җирле үзидарә органындагы һәм Сайлау комиссиясе Аппараты Җирле үзидарә органындагы вазыйфа.

**56 статья. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр.**

1. Муниципаль вазыйфаны биләүче затлар - җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты: җирлек башлыгы.

2. Муниципаль хезмәткәр булып федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә эш үтәүче, җирле бюджет акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата хезмәт вазыйфасын башкарган граждан тора.

3. Җирле үзидарә органнары, Җирлекнең сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын үтәмиләр һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормыйлар.

**57 статья. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары.**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хезмәткәрнең аның муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, вазыйфаи бурычларын үтәүнең сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча алга китү шартлары белән танышу;

2) вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле оештыру-техник шартларны тәэмин итү;

3) хезмәт хакы һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт шартнамәсе (контракт) нигезендә башка түләүләр;

4) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәрен һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрен бирү, шулай ук еллык түләүле отпускны тәэмин итү;

5) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алу, шулай ук җирле үзидарә органы, Сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү;

6) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста үз инициативасы белән катнашу;

7) Җирлекнең муниципаль хокукый акты нигезендә, Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә һөнәри белем алу;

8) шәхси мәгълүматларын яклау;

9) үзенең шәхси эшенең барлык материаллары, шәхси эш кенәгәсенә кертелгәнче, һөнәри эшчәнлегенә бәяләмәләр һәм башка документлар белән танышу һәм шулай ук аның шәхси эшенә язма аңлатмаларын да җәлеп итү;

10) берләшмә төзү, һөнәри берлекләр төзү хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен;

11) хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт бәхәсләрен карау, муниципаль хезмәттә үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларның бозуларына карата судка шикаять белдерүне дә кертеп;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэмин итү.

2. Муниципаль хезмәткәр, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүче) алдан язмача хәбәр итеп, әгәр бу мәнфәгатьләр

конфликтына китермәсә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законда башкасы каралмаса, башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Муниципаль хезмәткәр мәҗбүр:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасының законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларны башкарырга;

3) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә кешенең һәм гражданның, расага, милләтенә, теленә, дингә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, Поселения сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе, вазыйфаи инструкция кагыйдәләрен, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларны тиешенчә башкару өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен тәэмин итүгә;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагыла торган белешмәләрне фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән аңа вазыйфаи бурычларны башкару өчен бирелгән мөлкәтне сакларга;

8) үз гаиләсенең үзе һәм әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу көнендә яисә чит ил гражданлыгы алынган көндә чит ил дәүләте гражданлыгын алу турында хәбәр итәргә;

10) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, йөкләмәләрне үтәргә, тыюларны бозмаска;

11) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә язма рәвештә хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау чараларын күрергә.

4. Муниципаль хезмәткәр үзенә бирелгән хокуксыз йөкләмәне үтәргә хокуксыз. Тиешле җитәкчедән муниципаль хезмәткәр фикеренчә, хокуксыз булган йөкләмәне алганда, муниципаль хезмәткәр, йөкләмә биргән җитәкчегә, әлеге йөкләмәне үтәгәндә бозылырга мөмкин булган Россия Федерациясенең федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезләмәләрен күрсәтеп, муниципаль хокукый актлар нигезләмәләрен күрсәтеп, әлеге йөкләмәнең хокуксызлыгын нигезләүне аңлатып язма рәвештә хәбәр итәргә

тиеш. Әлеге йөкләмә аны бирүче җитәкче тарафыннан язма рәвештә раслаган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Хокуксыз йөкләмә үтәлгән очракта, аны башкаручы муниципаль хезмткәр һәм йөкләмә бирүче җитәкче, Россия Федерациясе законнары җыелмасы нигезендә җаваплы булалар.

**58 статья. Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр.**

1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләнә:

1) вазыйфаи инструкция нигезендә, аның вазыйфаи бурычларын үтәвен тәэмин итә торган эш шартлары;

2) үз вакытында һәм тулы күләмдә акчалата түләү алуга хокук;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәрен һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрен бирү, шулай ук еллык түләүле отпускны тәэмин итә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыкканнан соң да;

5) тиешле елларын эшләгән өчен һәм инвалидлыкка бәйле рәвештә пенсия белән тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларын вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә вафат булган очракта пенсия белән тәэмин итү;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерү очрагына мәҗбүри дәүләт иминләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәрләрнең, вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән, муниципаль хезмәт узу чорында авыруы яисә хезмәткә сәләтлелеген югалту очрагына яисә аны туктатканнан соң мәҗбүри дәүләт социаль иминиятләштерүе;

8) федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда аның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын көчләүдән, янаулардан һәм башка хокукка ия булмаган гамәлләрдән яклау.

2. Җирле үзидарә органы, Сайлау комиссиясе бетерелүгә йә җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә муниципаль хезмәткәргә Җирлек аппараты кыскартылганда, оешма бетерелүгә йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3.Әлеге Устав белән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.

**59 статья. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы.**

1. Дисциплинар гамәл кылган өчен - муниципаль хезмәткәрләргә аның өстенә йөкләнгән хезмәт бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен - яллаучы (эш бирүче) вәкиле түбәндәге дисциплинар түләтүләр кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә;

3) муниципаль хезмәт эшеннән тиешле нигезләрдә азат итү.

2. Дисциплинар гаеп эшләгән муниципаль хезмәткәр вакытлыча (ләкин бер айдан да артык түгел), аның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәләне хәл итүгә кадәр, хезмәт бурычларын үтәүдән акчалата түләүне саклап калу белән читләштерелергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне вазыйфаи бурычларын үтәүдән читләштерү бу очракта муниципаль хокукый акт белән башкарыла.

3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә.».

**8. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының VIII, IX, X, XI, XII, XIII, XIV бүлекләрен «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының IX, X, XI, XII, XIII, XIV, XV бүлекләре дип санарга.**

**10. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 71 статьясына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«71 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе.**

1. Җирлек Советы карарлары Җирлек Башлыгы кул куйган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә, әгәр дә карар белән башкасы билгеләнмәгән булса.

Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Советының авыл җирлеге уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары Федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек Башлыгының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актлар үзләре тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, аларны имзалаган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актны яисә килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук “Интернет” челтәре басмасыннан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, басмада аңа карата күләмле график һәм таблицалы кушымталар китерелмәскә мөмкин.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, имза салу датасы (Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен - шулай

ук аны Җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актны имзалаган вазыйфаи зат исеме, матбугат булырга тиеш.

5. Җирлекнең бюджет турындагы карары, аның үтәлеше турындагы хисап, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карар, Җирлек Советы Регламенты, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль норматив хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларны имзалаган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Мәҗбүри рәвештә официаль басытырып чыгарырга (халыкка җиткерелергә) тиешле документлар булып шулай ук саналалар муниципаль сайлаулар,җирле референдум, Җирлек Советына депутат чакырту буенча сайлаулар, чикләрне үзгәтү буенча сорау, Җирлекне үзгәртеп кору, Җирлек Башлыгы һәм аның урынбасарын сайлау һәм законнар нигезендә булган башка хокукый актлар.

7. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мәҗбүри булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган органнар яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

8. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль хокукый актларны, килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган басма массакүләм мәгълүмат чараларында йә җирлек территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында хокукый акт текстын бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында тамга булырга тиеш;

- җирлек халкына, шул исәптән махсус басма рәвешендә хокукый акт текстын үзәкләштерелгән тәртиптә тарату (тарату);

- җирлекнең торак пунктлары территориясендә хокукый акт текстын махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Күрсәтелгән стендлар һәм аларның урнашу урыннары саны җирлек Советы тарафыннан раслана һәм җирлек халкының муниципаль хокукый акты тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә районның рәсми сайтында урнаштыру (http://tulachi.tatarstan.ru);

- хокукый акт текстын «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча урнаштыру: http://pravo.tatarstan.ru.

Муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Юстиция министрлыгы порталында дәүләт теркәве узганнан соң рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә)

хокуклы (http://pravo-minjust.ru, http://хокук-минюст.рф, челтәр басмасы буларак теркәлү: 77-72471 05.03.2018).»

9. Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасының чыгу датасы яисә тиешле актны халыкка җиткерү датасы турында белешмәләр күрсәтелергә тиеш, алар актны җибәрә (таратыла) башлау яисә аны мәгълүмат стендында урнаштыру датасына туры килергә тиеш.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарларның хокукый актлары рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

11. Әлеге карарны, билгеләнгән законнар нигезендә, дәүләт теркәвенә җибәрергә.

12. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендәге махсус мәгълүмат стендаларында урнаштыру, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә «Татарстан республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда веб адресы: http://pravo.tatarstan.ru буенча, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында веб адресы: http://tulachi.tatarstan.ru буенча кую юллары аша халыкка җиткерергә.».

13. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан республикасы
Теләче муниципаль районы
Олы Нырсы авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Гиниев